**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 31 декабрендәге ПУ-713 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 31 октябрендәге ПУ-688 номерлы, 2013 елның 26 декабрендәге ПУ-1276 номерлы, 2014 елның 1 сентябрендәге ПУ-829 номерлы һәм 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1193 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 29 декабрь
№ ПУ-1174

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 29 » декабрендәге
ПУ-1174 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы структурасы

**Министр**

- Министр ярдәмчесе
- Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге
- Кадрлар сәясәте бүлеге
- Юридик бүлек
- Махсус эш һәм мобилизация эше секторы
- Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты
  - Министр урынбасары – Департамент җитәкчесе
  - Җитәкче урынбасары
  - Мәгариф өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге бүлеге
  - Белем бирү сыйфатына дәүләт контроле бүлеге
  - Мәгариф эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе бүлеге
  - Мәгариф эшчәнлеген лицензияләү бүлеге
  - Мәгариф оешмаларына лицензия контроле бүлеге
  - Белем һәм (яисә) квалификация турындагы документларны раслау бүлеге
  - Хокукый җайга салу бүлеге
  - Аналитик, мәгълүмати һәм оештыру ягыннан тәэмин итү бүлеге
- Министрның беренче урынбасары
  - Һөнәри белем бирү идарәсе
  - Югары белем бирү бүлеге
  - Урта һөнәри белем бирүне үстерү бүлеге
  - Халыкара мәгариф программалары һәм проектлары бүлеге
  - Фәнни-техник сәясәт бүлеге
  - Фәнни оешмалар эшчәнлеген җайга салу секторы
- Министрның беренче урынбасары
  - Гомуми белем бирү идарәсе
  - Гомуми белем бирү һәм укучыларга йомгаклау аттестациясе уздыру бүлеге
  - Мәктәпкәчә белем бирү бүлеге
  - Мәгълүмати технологияләрне үстерү һәм куркынычсызлык бүлеге
  - Милли мәгариф идарәсе
  - Милли мәгариф бүлеге
  - Төбәкара хезмәттәшлек секторы
  - Белем бирү процессын укыту-методик тәэмин итү секторы
- Министр урынбасары
  - Балаларга өстәмә белем бирү бүлеге
  - Дәрестән тыш һәм сәламәтлекне саклау эшчәнлеге программаларын гамәлгә ашыру секторы
  - Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге
- Министр урынбасары
  - Өстәмә һөнәри белем бирүне үстерү бүлеге
  - Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек буенча әйдәүче киңәшче
  - Эшләр идарәчесе
  - Оештыру бүлеге
  - Гомуми бүлек
  - Техник һәм хуҗалык тәэминаты бүлеге
- Министр урынбасары
  - Планлаштыру һәм хезмәткә түләү бүлеге
  - Уку-укыту процессын матди тәэмин итү һәм хезмәтне саклау бүлеге
  - Дәүләт программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыру бүлеге
  - Дәүләт заказларын тәэмин итү бүлеге